РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«19» ноябрь 2024 ел г. Альметьевск № 3687

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «2024 елга Әлмәт муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалауның муниципаль программасын раслау турында» 2023 елның 22 декабрендәге 8398 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Төзәтүләр тәртибендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «2024 елга Әлмәт муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалауның муниципаль программасын раслау турында» 2023 елның 22 декабрендәге 8398 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 14 июнендәге 2095 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 1 нче кушымтасында:

- Программа паспортының «Муниципаль программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Программаны җирле бюджет акчалары хисабына финанслауның гомуми күләме 8 448,142 мең сум тәшкил итә.<br><br>Искәрмә:* программаны муниципаль бюджет акчалары хисабына финанслау күләме фаразлау характерында һәм реаль мөмкинлекләрдән чыгып төгәлләнергә тиеш. |

- «Программаны ресурслар белән тәэмин итүне җайга салу» 3 бүлегенең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программаны җирле бюджет акчалары хисабына финанслауның гомуми күләме 8 448,142 мең сум тәшкил итә.»;

2024 елга Әлмәт муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалауның муниципаль программасы кушымтасында:

- «6 нчы бурыч: Әлмәт муниципаль районында хокук тәртибен профилактикалау өлкәсендә хокук саклау органнары хезмәткәрләренең потенциаль мөмкинлекләрен эшләү һәм гамәлгә ашыру өчен бүләкләү

заказ № 1-851

системасын булдыру» бүлегенең 6.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 6.1 Хокук саклау органнары хезмәткәрләре арасында конкурс үткәрү | ТР ӘМР БК | 2024 | | | | 4 678,142 |

- «2024 елга барлыгы» юлын: Җирле бюджет акчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| 2024 елга барлыгы:<br>Җирле бюджет акчалары: | 8 448,142 |

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Район Башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы А. М. Каюмов